УДК 76.03

***М.Р. Газизова***

# 1920–1930 ЕЛЛАРДА «ЧАЯН» ЖУРНАЛЫ БИТЛӘРЕНДӘ ХАЛЫКАРА СӘЯСИ САТИРА

Статья посвящена сатирической графике Татарстана 1920–1930-х годов. Автор анализирует развитие международной темы на страницах журнала «Чаян», показывает изменение тематики в зависимости от особенностей международной политики и интересов государства, выделяя два периода – 1920-е и 1930-е годы. Эти же периоды отражают и художественные особенности журнала, характеризующиеся ограниченным кругом художников и их полупрофессиональным уровнем в 1920-е годы, работой большого числа профессиональных мастеров сатирической графики — в 1930-е годы.

**Ключевые слова и фразы:** сатирическая графика; международная политическая сатира; журнал «Чаян»; искусство Татарстана.

Совет хакимиятенең беренче елларында карикатура массакүләм агитация сәнгатенең төп өлешен били. Яңа җәмгыятьне актив пропагандалау һәм аның дошманнары белән көрәш карикатура ярдәмендә алып барыла. «Советская карикатура [20-е годы XX века] набирала тогда высоту. Ещё совсем молодая, она с каждым днем становилась все более зрелой. С первых дней своих была искусством переднего края. В этом ее сила. И основа ее притягательности» [Елькович, 1977, с. 5]. Сатирик рухтагы вакытлы матбугат басмалары күренә башлый: мәсәлән, «Крокодил» (Мәскәү, 1922), «Прожектор» (Мәскәү, 1923), «Мыштым» (Үзбәкстан, 1923), «Нианги» (Грузия, 1923). Татарстанда 1923 елдан айга бер мәртәбә сатирик «Чаян» журналы чыгарыла башлый (ул үз эшен әле дә дәвам итә). Бу журнал башта татар телендә генә нәшер ителә, ә 1956 елдан башлап, шул ук исемдә рус телендә дә басыла.

«Чаян», «Нианги», «Мыштым» кебек милли басмалар Россиядә инкыйлабка чаклы ук эшләп килүче сатирик журналистиканың дәвамчылары булалар. «Чаян», XX гасыр башында Г. Камал һәм Г. Тукай тарафыннан нигез салынган «Яшен» (1908–1909) һәм «Ялт-Йолт» (1910–1918) журналлары кебек, татар сатирик басма графикасы традициясен дәвам итә. «Появление печатных периодических изданий сатирического направления на татарском языке было не случайным, так как в самой культуре народа, его фольклорных произведениях средствами юмора и сатиры бичевались негативные явления, проявлявшиеся в обществе [Вагапова, 2011 с. 277].

Сатирик «Чаян» журналы таралышы белән ил башкаласы басмаларыннан калышмый, татар халкы арасында киң таныла. С.М. Червонная язганча, «В первые годы профиль журнала почти целиком определяла

«внутренняя» тематика, бытовая сатира, международной темы он касался редко. Тогда журнал имел свой ярко выраженный национальный колорит» [Червонная, 1987, с. 226]. Шуңа да карамастан, 1920 елларда, аеруча 1930 елларда журнал битләрендә татар сатирик графикасының инкыйлабка кадәрге чоры традицияләрен дәвам иткән халыкара тематика шактый урын алып тора. Тик бу тема сәнгать фәне тикшеренүләреннән ерак китми, шуңа күрә алар тагын да җентекләбрәк өйрәнеп тикшерүне таләп итә. Татарстан сатирик графикасының Совет чоры С. Червонная, Л. Елькович, А. Файнберг кебек сәнгать белгечләре хезмәтләрендә анализлана. Әмма аларның тикшеренүләре 1970 еллар белән тәгәлләнә, шуңа күрә Татарстанның карикатура сәнгате яңача, бүгенге күзлектән чыгып бәяләүне көтә.

Сатирик журналлар халыкның киң катлавына тәкъдим ителгәнлектән, андый басмаларда текстка караганда рәсемнәргә өстенлек бирелә. «Чаян»га да шул ук сыйфатлар хас. 1920 елларда милли үзаң күтәрелеше көчәя һәм журнал битләрендә милли тематика белән бәйле карикатуралар бастырыла.

1920 елларда «Чаян» рәссамнары гәүдәләндергән мөһим халыкара темаларга килгәндә, аларның шул чор өчен иң популяр булганнарын аерып күрсәтү кыен түгел. Алар, беренче чиратта, монархиянең бәреп төшерелүенә юнәлдерелә. Күп кенә карикатураларда Россия империясенең соңгы патшасы Николай II, аерым алганда, аның Көнбатыш белән мөнәсәбәтләре көлке объектына әверелдерелә, аның шаржлаштырылган портретлары, үзен сурәтләгән карикатур рәсемнәр басылып чыга. Тагын бер мөһим тема: Көнбатыш Европа белән Американың җимергеч сәясәте, аеруча аларның күтәрелеп килүче илләргә карата колониячел сәясәте. Өченче юнәлеш: капиталистик илләрдәге халыкара инкыйлаби хәрәкәтләр. 1930 елларда Германиядә, Италиядә, Испания һәм Япониядә фашистлар яклы режимның көчәюе сәбәпле, карикатур рәсемнәрнең күбесе фашизмга каршы көрәш темасына багышлана.

«Чаян» графикасы сәнгатьчә эшләнеше белән баштагы елларында (1923–1929/30 елларда) Мәскәү журналларыннан күпкә калыша. Чөнки анда әле тиешле дәрәҗәдә сәнгати белемгә ия булмаган рәссамнар эшли. Шуңа да карамастан, аларның һәркайсы кабатланмас образлар, оригиналь сюжетлар табарга, үзләренең шәхси сәнгати манераларын булдырырга омтыла.

Татарстан сынлы сәнгатендә Совет чоры милли осталарының иң беренчесе Арсланов Госман Вәли улы (1897–1941) була, ул җирле матбугатка хезмәт күрсәтүче бердәнбер рәссам санала [Дульский, 1930, с. 10]. Г. Арсланов «Чаян» белән аның беренче көннәреннән үк хезмәттәшлек итә, журналга урнаштырылган карикатураларның күбесе аныкы була. «Азам профессии художник обучился, беря частные уроки и посещая некоторое время Пермские художественно-

промышленные мастерские» [Дульский, 1930, с. 10]. Госман Вәли улының рәсем сәнгате буенча махсус белемгә ия булмавы, әлбәттә, рәсемнәрендә дә чагылыш таба: «Они были бы еще острей и выразительнее, если бы этот несомненно талантливый график подходил с большей требовательностью к их пластической стороне, к сатирической графике рисунка» [Елькович, 1977, с. 26]. Г. Арсланов һөнәри белем җитешсезлеген карикатураларында үткен сатирасы һәм мәгънәви көлкеле сурәтләре, көтелмәгән чагыштырулары, оригиналь композицияләре, тасвирый чаралар төрлелеге белән тулыландыра. Ул персонажларны сурәтләүдә гротескка мөрәҗәгать итә, рәсемнәренең сатирик көчен төрле төстәге җете ачык буяулар белән арттыра, һәр детальне, киемнәрне бөтен нечкәлекләре белән җентекләп ясый. Г. Арсланов сатирик графиканың төрле формаларын – плакат характерындагы карикатуралар да, үзенчәлекле комикслар да (рәсемдәге күренешне хикәяләгән текстлы басмалар), аерым кешеләрнең портретларын шаржлап бирүне һ.б.ларны куллана. Рәссам Россиянең һәм Татарстанның сынлы сәнгать һәм матур әдәбият классиклары образларыннан еш файдалана. Мәсәлән, аның «Империализмга һәйкәл» карикатурасы [Арсланов, 1924, № 13, тышлык] нигезен В.В. Верещагинның «Апофеоз войны» картинасы сюжеты тәшкил итә: Николай II не, тәхет урынына, кешеләрнең баш сөякләре өеменә утырып сурәтли ул. «Халыкара печән базары» карикатурасы исә Г. Тукайның татар җәмәгатьчелегенә киң мәгълүм «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» сатирик поэмасын хәтерләтә [Арсланов, 1933, с. 7].

Г. Арсланов заманының һәр яңалыгын бик тиз тотып ала. Әйтик, «Чаян» журналының 1926 ел, 6 нчы, 7 нчы һәм 1927 ел, 12 нче саннары тышлыгына Төркия солтанлыгының таркалуына кагылышлы карикатураларын урнаштыра. Аларда соңгы төрек солтанының, качып, башка илләрнең үзен сыендыруларын сорануы, мескенлеккә төшүе тасвирлана. Европадагы социаль проблемаларны рәссам үзенең «Җанлы манекен» хезмәтендә сурәтли: кибет витринасында көннәр буе хәрәкәтсез басып торучы кызны – җанлы манекенны гәүдәләндерү аша, тыштан караганда якты төсләргә күмелгән Европадагы хатын-кызларның авыр хәлен чагылдырырга омтыла. Рәссам андагы шартларның һәр деталенә игътибар итә, витринаның бизәлешен, анда күрсәтелгән киемнәрне бөтен нечкәлекләре белән бирә. Авторның бу карикатурасында 1920 елларда Европада һәм Америкада киң таралыш яулаган арт-деко стиле йогынтысы да чалымлана. Шуны билгеләп үтәргә кирәк, 1920 еллар ахырында инде Г.В. Арсланов иҗатында аның һөнәри дәрәҗәсенең югары булуы сизелеп тора, чөнки ул графика өлкәсендә актив эшли, үз осталыгын камилләштерү белән даими шөгыльләнә.

1920 еллар ахыры – 1930 еллар башында «Чаян» журналы коллективы махсус белемгә

ия, талантлы рәссам-графиклар белән тулылана. Мәсәлән, анда П. Новичков, И. Бобровицкий, В. Кораблинов, Г. Поляков һ.б. эшли башлый.

Бу чорда журнал битләрендә халыкара тема көннән-көн зуррак урын били бара. Еш кына анда Мәскәү журналларыннан (мәсәлән, «Крокодил»дан) күчермәләр бастырыла. «Чаян»ның үз рәссамнары да, нигездә, Россиякүләм сатирик графика осталары Дмитрий Моор, Михаил Черемных, Виктор Дени һ.б. рәссамнар иҗатына юнәлеш тоталар. Шул ук вакытта алар дөнья сатирик графикасы классиклары, аеруча Франциянең төрле дәверләрдәге революцион рәссамнарына (Андре Жиль, Филипп Оноре һ.б.га) мөрәҗәгать итәләр.

1930 елларның беренче яртысында журналдагы күп кенә карикатуралар Г. Поляков (≈1901–1949) тарафыннан иҗат ителә. Ул Казан сәнгать училищесын тәмамлый, Революцион Россия рәссамнары ассоциациясендә әгъза булып тора. Г. Поляков «Чаян» журналы белән 1920 еллар ахырыннан хезмәттәшлек итә. С. Червонная аның иҗатын болай характерлый: «В его рисунках привлекает крепкая, чёткая, ритмическая слаженность композиции, своеобразная монументальность формы, живописность в передаче пространственной среды» [Червонная, 1975, с. 244]. Г. Поляков карикатуралары оригиналь табышлары һәм көтелмәгән чишелешләре белән аерылып тора. Ул беренче булып «Чаян»да фотомонтаж техникасын куллана башлый. Шул ысулдагы «Сүзсез» («Без слов») карикатурасында рәссам [Поляков, 1933, с. 4] шул чорда киң таралган революцион сатира сюжетын – ике дөнья (социализм белән капитализм) антогонизмын нигез итеп ала. Ак-кара сызылмалы рәсем фотографик сурәтне имитацияли.

1935–1936 елларда дөньякүләм сәяси графика Италиянең Эфиопиягә бәреп керүенә каршы күтәрелә. Бу темага Г. Поляков «Җиләк-җимешләр илендә» («Во фруктовой стране») рәсемен иҗат итә [Поляков, 1933, с. 4]. Рәссам Муссолининың шарж рәвешендәге символик образы аша фашистлар режимы сәясәтен яктырта. Карикатурада табутны хәтерләткән әрҗәләрдәге кеше башы сөякләре – «Яңа төрле җиләк-җимешләр»нең аллегорик жанр ярдәмендә сурәтләнүе әсәрнең драматизмын тагын да көчәйтә. Г. Поляковның бу карикатурасы, ак-кара төсләр белән генә эшләнсә дә, рәсем сәнгатендә тирән психологик образлар тудыруга ярдәм итә торган тәэсирле һәм үтемле детальләр сайлый белүе белән игътибарны бик тиз җәлеп итә.

1932 елда «Чаян» журналы битләрендә Н. Борисовның көлкеле рәсемнәре басыла башлый. Аның Октябрь революциясенең 15 еллыгына багышланган иҗаты аеруча уңышлы санала. Рәссам совет сәнгате өчен иң популяр мотивны – капитализмның җимерелүен аеруча уңышлы гәүдәләндерә: ул аны кызу тизлек белән упкынга таба чабып баручы машина рәвешендә сурәтли. Әсәрнең композициясе төрле

якка юнәлгән диагональләрне чагыштырма планда күрсәтүгә нигезләнгән. Мәсәлән, упкынга ыргылучы машина ярдәмендә ул Көнбатыш илләр җитәкчеләрен, ә кызыл флаг җилфердәтеп алга-югарыга омтылган поезд аша революциянең җиңеп чыгуын гәүдәләндерә. Ак-кара сызылмалы рәсемне кызыл төс белән төрләндерү күңел күтәренкелеге һәм якты өмет рухы өсти [Борисов, 1932, с. 10].

1939 елда «Чаян» белән үткен сәяси фикерле рәссам-график В. Кораблинов хезмәттешлек итә. Ул фәкать халыкара темаларны гына күтәрә: «С его приходом международная политическая карикатура “Чаяна” делает заметный качественный скачок» [Елькович, 1977, с. 48]. Үзенең «Бераз геометрия белән мавыгу» («Небольшое увлечение геометрией») дип аталган хезмәтендә автор фашистлар режимының ерткычлыгын сурәтләргә омтыла. Очларында Германия, Италия һәм Япония лидерлары утырган үзенчәлекле өчпочмаклыкның, шушы илләр сәясәте нәтиҗәсендә һәлакәткә дучар ителүе сурәтләнә. В. Кораблинов карикатуралары вакыйгаларны, сәяси күренешләрне турыдан-туры түгел, ә читләтеп, символик формада чагылдыра. Ул гротескка кыю мөрәҗәгать итә: сәяси процессларның, аерым шәхесләрнең һәм вакыйгаларның тискәре якларын чиктән тыш күпертеп, ассызыклап күрсәтә белә. (Соңыннан бу автор, Воронежга китеп, әдәбият өлкәсендә эшли.)

«Чаян» журналының тәүге саннары өчен карикатуралар өйрәнчек рәссамнар тарафыннан да эшләнә. Соңыннан аларның күбесе сатира осталары булып танылалар. Шундыйларның берсе – Павел Тихонович Новичков (1909–1968). Ул Бөек Ватан сугышыннан соңгы елларда журнал эшчәнлеген торгызу буенча зур хезмәт куя һәм сатирик графика традицияләрен саклауга һәм үстерүгә аеруча игътибар бирә. Озак кына вакытлар «Чаян»ның художество редакторы була. Аның «Туган илен саткан кешеләр» («Люди, которые продали Родину») рәсеме тирән мәгънәгә ия [Новичков, 1937, с. 9]. Башка күп кенә карикатурачылар кебек үк, ул да иҗатында фантасмагорик образлардан файдалана. Фашистларның хәрби башлыкларын П. Новичков канга сусаган, коточкыч куркыныч, кеше башлы ерткычлар рәвешендә гәүдәләндерә. Рәссам үзенең сатирасында чынбарлык белән фантастиканы оста итеп үреп бирә белә, кешеләрнең йөзләренә, фигураларына һәм киемнәренә игътибарны көчәйтү өчен чамасыз арттырып җибәрүләргә бара.

«Чаян» журналы белән хезмәттәшлектәге сатириклар һәм карикатурачылар арасында иң көчле иҗатчы Иосиф Ефимович Бобровицкий (1904–1986) була. Ул Казанга 1935 елда Бакуның «Вышка» газетасындагы эшен калдырып килә. И.Е. Бобровицкий күп фигуралы катлаулы композицияләргә мөрәҗәгать итә, аның карикатураларының күбесендә берничә вакыйга, күп предметлар һәм детальләр яктыртыла. Моңа мисал итеп, рәссамның Икенче Бөтендөнья сугышы

башланыр алдыннан гына иҗат иткән, фашизмга каршы юнәлдерелгән «Время очередной кормёжки хищников» сатирик әсәрен китерергә була [Бобровицкий, № 7, тышлык]. Плакат стилен хәтерләткән бу рәсемнең композициясендә силуэт-күләм кушылмасы файдаланылган, һәм ул сурәткә киңлек һәм тәэсирлелек өсти.

Димәк, «Чаян» сатирик журналы, чыга башлаган көненнән бирле, илдәге һәм республикадагы эчке проблемаларга гына түгел, халыкара сәяси темаларга да зур урын бирә. Басмага мөрәҗәгать итү активлыгы һәм аның проблематикасы тарихи вакыйгаларга бәйле рәвештә үзгәреп тора. 1920 елларда «Чаян» битләрендә күтәрелгән төп темалардан, әйтеп үтелгәнчә, Россия монархиясенең җимерелүен, Көнбатыш Европа белән Американың күтәрелеп килүче илләргә карата колониячел сәясәтен атарга була. Карикатураларның өченче юнәлешен – зур күпчелеген – революцион хәрәкәт тәшкил итә.

1920 елларда журналда, нигездә, махсус белеме булмаган рәссамнар эшләгәнгә күрә, анда басылган сатирик әсәрләр тиешле югарылыкта булмый әле. Ә инде, әйтеп үтелгәнчә, 1920 еллар ахырында аларга яхшы һөнәри әзерлекле карикатурачылар килеп кушыла. Һәм сатирик графика өлкәсендә зур тәҗрибә туплап килгән П. Новичков, И. Бобровицкий, В. Кораблинов һ.б. авторлар ярдәмендә «Чаян» журналы үзенең эчтәлеген сәнгатьчә югары дәрәҗәгә күтәрүгә ирешә дә.

**Әдәбият**

*Арсланов Г.В.* Живые манекены [рисунок] // Чаян. 1935. № 7–8.

*Арсланов Г.В.* Памятник империализму [рисунок] // Чаян. 1924. № 13.

*Арсланов Г.В.* На международном Сенном рынке [рисунок] // Чаян. 1933. № 11–12.

*Бобровицкий И.Е.* Время очередной кормежки хищников [рисунок] // Чаян. 1939. № 7.

*Борисов Н.* Без слов [рисунок] // Чаян. 1932. № 10–11.

*Вагапова Ф.Г.* Синтез традиций в оформлении дореволюционных татарских сатирических журналов // Филология и культура. 2011. № 26. С. 277–280.

Дульский П. М. Оформление татарской книги за революционный период. Казань: Татполиграф, 1930. 24 с.

*Елькович Л.Я.* На линии огня. Казань: Таткнигоиздат, 1977. 126 с.

*Кораблинов В.* Небольшое увлечение геометрией [рисунок] // Чаян. 1939. № 6.

*Новичков П.Т.* Люди, которые продали Родину [рисунок] // Чаян. 1937. № 2.

*Поляков Г.Я.* Во фруктовой стране [рисунок]// Чаян. 1933. № 1.

*Червонная С.М.* Искусство Татарии. М.: Искусство, 1987. 352 с.

*Червонная С.М.* Художники Советской Татарии. Казань: Таткнигоиздат, 1975. 212 с.

***Газизова Марина Ринат кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли*
*сәнгать бүлеге фәнни хезмәткәре*



Г.В. Арсланов.
(Чаян) 1927. № 12.



Н. Борисов
(Чаян) 1932. № 10–11.



Г.Я. Поляков.
(Чаян) 1933. № 1.



Г.В. Арсланов.
(Чаян) 1933. № 11–12.
На международном
Сенном рынке



П.Т. Новичков.
(Чаян) 1937. № 2.
Люди, которые продали
Родину



Ф.В. Кораблинов.
(Чаян) 1939. № 6
Небольшое увлечение
геометрией



И.Е.Бобровицкий.
(Чаян) 1939. № 7
Время очередной кормежки
хищников



Г.Я. Поляков.
(Чаян) 1939. № 1
Во фруктовой стране